**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «НИЖНЕЧЕРШИЛИНСКОН СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ТҮБӘН ЧЫРШЫЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2018 елның 7 ноябре** **№ 42**

Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2012 елның 10 декабрендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2018 елның 31 июлендәге 5 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2012 елның 10 декабрендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан

Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2018 елның 31 июлендәге 5 номерлы «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«административ регламент - дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен һәм дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын билгеләүче норматив хокукый акт».

2. Әлеге карарны Түбән Чыршылы авыл җирлеге буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы

Лениногорск муниципаль районы

«Түбән Чыршылы авыл җирлеге»

муниципаль берәмлеге башлыгы Н.Я.Хәйруллина